ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**7 февраль 2019 ел** **№ 12**

**«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линияле объектын төзү территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Айван авылына газүткәргеч кертү» гавами тыңлаулар уздыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы уставы, Арча муниципаль районы Советының 2008 елның 27 декабрендәге 220 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линияле объектын төзү территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Айван авылына газүткәргеч кертү» гавами тыңлаулар үткәрергә (1нче кушымта):

2. Билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 10.03.2019 ел, 13.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Арча муниципаль районы башкарма комитеты бинасы, адресы буенча: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт;

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр тапшырылырга,гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирелергә мөмкин булган адрес: ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (эш көннәрендә – 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.4. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - 07.03.2019 елга кадәр (тел. 3-12-44).

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм карарның билгеләнгән тәртибенә туры китереп, билгеләнгән срокларда үткәрергә.

4. Әлеге карарны 2018 елның 11 февраленә кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриев